Әдәби тәрҗемә – халыкның мәдәни тормышында, әдәби барышында ирешкән казанышларын башка халыкларга җиткерергә, шуның аша төрле халыкларның бер-берсен аңлауларына ирешүгә этәреш ясый торган иң мөһим алым. Милли мирас белән алмашу әдәби һәм мәдәни диалогка китерә. Автор тарафыннан татар әдәбиятын төрки халыклар һәм, гомумән, дөнья әдәби пространствосына чыгару, таныту мәсьәләсе дә күтәрелә.

Мәкаләдә Аяз Гыйләҗев әсәренең төрек укучысы тарафыннан уңай кабул ителүенең төп шартлары, татар чынбарлыгын чагылдырган һәм тәрҗемәдә генә җиткерелгән әсәрнең төрек укучысына психологик яктан тәэсире, сугыш темасының башка төрки халыкларны да битараф калдырмавы, татар халкының гореф-гадәтләре төрек аудиториясендә дә аваздашлык табуы ачыклана. Әсәр теленең тәрҗемәдә дә төп нөсхәдәге тәэсирлелеген югалтмавы, тәрҗемәченең язучы фикерен бөтен тирәнлеге, бөтенлеге белән җиткерү сәләтенә ия булуы билгеләнә.

**Төп төшенчәләр:** Аяз Гыйләҗев, татар прозасы, повесть, әдәби тәрҗемә, Фатих Кутлу, әдәбиятта сугыш темасы

## Кереш

Сүз сәнгате булган әдәби әсәр аерым тел кысалары белән чикләнгән һәм ул әлеге телне белгән, аның бөтен нечкәлекләрен аңлаган укучы тарафыннан гына кабул ителә ала. Бер халык вәкилләре тарафыннан тудырылган әдәбиятны башка халыкларга, башка мохиттә, башка мәдәни кыйммәтләр кысаларында тәрбияләнгән укучыга, нигездә, әдәби тәрҗемәдә генә җиткерергә мөмкин. Татар

әдәбияты соңгы ике дистә елларда бу өлкәдә шактый уңышлы адымнар ясады. Татар телендә язылган әдәбият үрнәкләре аеруча тугандаш төрки халыклар – азәрбайҗан, казах, каракалпак, якут һ. б. телләргә, аеруча актив рәвештә төрек теленә тәрҗемә итеп бастырылды. Әлеге юнәлештәге эшчәнлекнең алшартлары һәм нәтиҗәләре мәкалә авторы тарафыннан башкарылган алдагы хезмәтләрдә дә чагылыш тапты [1], [2], [3], [4], [5], [6], [7], [8], [9].

Төрек теленә соңгы чорда иң күп тәрҗемә ителгән татар язучыларының берсе буларак, һичшиксез, Аяз Гыйләҗев исемен атарга мөмкин. Мәшһүр язучы үзе исән вакытта булган сөйләшүе-аралашуы Фатих Кутлуның киләчәктә тәрҗемәчелек эшенә керешүенә йогынты ясый. Бу юнәлештә беренче омтылыш – прозаикның киң катлам татар укучысына танылган, XX гасырның икенче яртысы татар әдәбияты тарихының күркәм үрнәкләре исемлегендә лаеклы урынны алган повесте – фәлсәфи тирәнлек белән катлаулы сынау елларын узган татар кешесенең рухи халәтен ачуга юнәлдерелгән «Өч аршын җир» («Bir avuç toprak», 2008; 2011) әсәрен тәрҗемә итүдән башланды [10]. Күпмедер вакыттан соң тәрҗемәче тарафыннан бер-бер артлы А. Гыйләҗевның «Җомга көн, кич белән...» («Cuma günü, akşam...», 2013) [11], «Язгы кәрваннар» (“Bahar kervanlari», 2018) [13] , «Яра» (“Yara”, 2018) [13] әсәрләре тәрҗемә ителеп, Төркиядә дөнья күрде, төрек укучыларына тәкъдим ителде.

Әдәби тәрҗемәләрне өйрәнүче галимнәр өчен – әсәрнең икенче мәдәни чынбарлыкта яшәве, үз укучысын табуы проблемасын өйрәнү аеруча кызыклы мәсьәлә. Әлеге мәкаләдә куелган төп максат та – А. Гыйләҗевның «Яра» («Yara», 2018) [13] повесте мисалында татар әдәбияты үрнәкләренең төрек аудиториясендә яшәве-таралуын, укучы тарафыннан кабул ителүен, нинди тәэсир калдыруын бәяләүдән гыйбарәт. Совет чорында аралар ераклашкан, татар халкы тарихыннан хәбәрдар булмаган, тоталитаризм шартларында милли яшәешебезнең, гореф-гадәтләребезнең сакланышы асылын, нечкәлекләрен белмәгән, аңламаган чит ил аудиториясенә татар язучысының сүзе бөтен тирәнлеге белән ирешерме, аларны да дулкынландырырмы, сәнгати яктан тәэсир итәрме дигән сораулар, әлбәттә, тәрҗемәчене дә, бу мәсьәләне өйрәнүче галимнәрне дә борчый. Әсәрнең чагыштырмача соңгы вакытта тәрҗемә ителүе, ягъни вакыт аралыгының кыска булуы – әлеге кызыксынуны аеруча арттыра, мәсьәләне актуальләштерә.

Алдарак тәрҗемә ителгән әсәрләренә мөрәҗәгать итсәк, язучының «Өч аршын җир» повесте төрек укучылары тарафыннан югары бәяләнеп, Ч. Айтматовның «И дольше века длится день» («Елдан озын көн») романы белән бер дәрәҗәдә кабул ителүенә игътибарны юнәлтергә мөмкин. 2012 елда А. Гыйләҗевның әлеге әсәренең тәрҗемәсе Евразия Язучылар берлегенең төрки телләрдән төрекчәгә иң яхшы тәрҗемә ителгән әсәре буларак билгеләп үтелде. Әсәргә язылган дистәләгән бәяләмәләр шул хакта сөйли. Төрек язучысы Назмия Данизер укучыларда туган җиргә мәхәббәт, һәр инсанның туган җире һәм ата-анасы каршындагы бурычы турында искә төшерүгә юнәлтелгән геройларның психологик характеристикасын бирүдә авторның осталыгын ассызыклый. «Өч аршын җир» повестен укыгач, Таһир Танер А. Гыйләҗевны «татар Стендале» дип атый. Аны әсәрнең проблематикасы, татар язучысының фәлсәфи фикерләү киңлеге сокландыра [3, б. 56].

Шул рәвешле, Аяз Гыйләҗевның тәрҗемә ителгән беренче әсәре төрек укучылары аудиториясендә бер вакыйга буларак кабул ителде, татар тормышына әдәби ачкыч кебек игътибар үзәгендә торды, үз укучысын тапты һәм галимнәр тарафыннан фәнни әйләнешкә кертелде дип ышанып әйтергә нигез бар.

**Тикшеренү материаллары һәм методлары**

Язучының «Яра» («Yara», 2018) повесте да укучыны битараф калдырмады. Бу фикернең хак булуын әсәргә мөнәсәбәттә язылган фикерләрнең шактый булуы раслый. Мәкаләнең өйрәнү объекты да – шушы кайтаваз, ягъни әлеге өйрәнелә торган әсәрнең тәрҗемәсенә мөнәсәбәтле язылган укучы фикере, төрек язучы-тәнкыйтьчеләре тарафыннан язылган мәкаләләр, студентлар аудиториясенең, галимнәрнең фәнни эшләре.

Тикшерү методлары өйрәнү объектының үзенчәлеген исәпкә алып сайланды: беренче чиратта, анализлауның культура-тарих, чагыштырма-тарихи методлары, әдәби әсәрне бәяләүдә шәрехләү-герменевтика алымы файдаланылды, шулай ук тарихилык һәм миллилек принциплары үзәктә тотылды.

**Фикер алышу**

А. Гыйләҗев бу әсәрен һәрвакыт аерым бер ярату белән телгә ала: «Җаныма иң якыны – «Яра» [14]. Әдип аны 1983 елда, совет җәмгыятендә әхлакый кризис көчәя барган вакытта ук язарга ниятләп куйган була. «“Яра” повесте ул – минем йөз аклыгым... Тәсбих төймәләрен саныйм да саныйм, сизәм: алар кимеп бара! Уңышлы әсәр – бәхетле картлык ул, гомерне озайтучы дәрман, иң мөһиме – киләчәк буыннарга васыять тә ул. Әле мин татарлар җирдә яшәр, татар яшәгәндә, «Яра» повестьлары онытылмас дип нык ышанам», – дип бәяли әсәрен язучы Т. Әйдигә язган хатында [15].

Татар укучылары бу әсәрне бик җылы кабул иттеләр. Галимнәр тарафыннан да бу повесть шактый өйрәнелгән [15], [16], [17], [18], [19], [20], [21].

Төп теманы ачу барышында игътибарны Чанер Алмаз (Caner Almaz) исемле китап укучының Интернет челтәрендәге сайтында тәкъдим иткән «Ortak Acıların Kitabı / Yara» («Уртак хәсрәтләр китабы / Яра») язмасы җәлеп итте. [22] Мәкаләсенең ахырында үзен «Okumayı ve yazmayı sever» ягъни «Укуны һәм язуны сөюче» дип тәкъдим иткән әлеге шәхес, мәкаләсенең исемен, безнең уйлавыбызча, анализлана торган әсәрнең чын асылын ачарлык, мәгънәле итеп биргән. Язмасында автор А. Гыйләҗевның «Яра» повесте белән танышу барышында туган фикерләре, татар язучысы иҗатына мөнәсәбәте, повестька бәйле уйланулары белән бүлешә. Язма авторы әлеге татар язучысы иҗаты белән беренче тапкыр гына очрашуы турында хәбәр итә; әсәр аша үзе өчен яңа дөнья – татар әдәбиятында әһәмиятле урын тоткан язучы иҗатын ачуы һәм әлегә кадәр шундый язучыны белмәве, танымавы өчен күңелендә үкенеч кебек бер хис тоюы хакында яза. Әсәрнең язылу вакыты, темасына тукталып үткәннән соң, Чанер Алмаз «Яра» әсәре тәэсирендә туган түбәндәге хакыйкатьне ача: «Сугышта катнашучыларның тормышы, үлемнәре, яраланулары; югалган кешелек тойгылары, артта (туган җирдә) калучыларның әрнүләре, яраткан уллары киткән юлдан күзен алмаган әниләр, аталар, хатыннар, балалар... Сугыш – кешелеккә кирәкмәгән (ихтыяҗы булмаган) бердәнбер әйбер. Сугыш тарафыннан тудырылган бер генә уңай әйбер дә юк. Сугыш кеше үлеменнән һәм яңа сугыштан башка һичбер әйбер тудырмый». («Savaşanların yaşadıkları, ölümleri, yaralanmaları; kaybolan insani duygular, geride kalanların elemleri, sevdiklerinin yolunu gözleyen anneler, babalar, eşler, çocuklar… Savaş, insanlığın ihtiyacı olmayan tek şey. Savaşın var ettiği iyi hiçbir şey yoktur. Savaş, insan ölümünden ve yeni bir savaştan başka hiçbir şey doğurmaz»).

Повестьтагы төп каһарман язмышын күздән кичергәннән соң, язма авторы әлеге әсәр аша татар халкының мәдәнияте белән танышу мөмкинлеген ассызыклый һәм төрек-татар халыклары мәдәниятендә бик күп уртак яклар барлыгын тоймыйча калып булмавын искәртә. Аеруча авыл тормышындагы уртаклыкларның әсәр буенча дәвам итүен билгеләп үтә. «Язучы Гыйләҗевның лирик теле укучыны үзенә тарта, сез герой тормышындагы хәсрәтләрне ничек булган, шулай күрәсез. Нәкъ шушы як сезне әсәргә «бәйләп куя». Сугышның уртак хәсрәт китерүе, һәр милләткә дә ясаган яралары бертөрле икнәлеге турында уйламыйча булдыра алмыйсыз. «Яра» – укучыны тирән тойгыларга салу көченә ия булган бер әсәр», – дигән йомгак ясый.

Язма белән танышканнан соң түбәндәге нәтиҗәгә киләбез: Чанер Алмаз, әдәбият сөюче төрек укучыларының берсе буларак, А. Гыйләҗевның «Яра» повестеның асылын, сугышның бары тик афәт, яра, хәсрәтләр генә китерүе хакындагы төп фикерен тирән аңлаган; үз дөньясы, үз халкының дөньяга карашын, мәдәни байлыгын күз алдында тоткан хәлдә, ике милләтнең яшәешендәге, дөньяга карашларындагы уртак якларны ачыклаган, бәяли алган. Ягъни әсәрнең тәрҗемәсе – максатына ирешкән.

Эсра Карадоган (Esra Karadoğan) «Savaşin Açtiği Büyük Yara» («Сугыш тарафыннан ясалган олы яра») [23] язмасы мәкалә авторының игътибарын тәнкыйди фикер үрнәге буларак җәлеп итте. Үз вакытында Төркиянең Анадолу лицеен (Anadolu Lisesi) һәм Истанбул университетын (İstanbul Üniversitesi) тәмамлаган, төрек аудиториясенә вакытлы матбугат битләрендә әдәби әсәрләргә рецензия-бәяләмәләре белән танылган әлеге ханымның «Яра» повестеның төрек телендә тәрҗемәсе басылып чыкканнан соң (29 март 2018) дөнья күргән мәкаләсе беренче җөмләсеннән үк укучы игътибарын җәлеп итә: «Яра» минем беренче тапкыр укыган, Аяз Гыйләҗевның Фатих Кутлу тарафыннан төрекчәгә тәрҗемә ителгән дүрт китабының берсе. Әлегә кадәр таныш булмаган бер язучының китабын уку нәтиҗәсендә, бер дә икеләнмичә шуны әйтә алам: «Яра» – укучының күңелен biләп ала

торган, чынбарлыктан алынган хикәя. Китапта беренче юлларыннан ук өстенлек иткән сагыш сезне чорнап ала. Бу сагыш сугыш шартларында яшәүчеләргә бәйле» (*«Yara benim de ilk kez okuduğum yazar Ayaz Ğıylecev'in Fatih Kutlu tarafindan Türkçe'ye çevrilen dört kitabından biri. Henüz tanımadığım bir yazarın kitabını okurken bazı tereddütlerim olmuyor değil ama Yara, okuru saracak, gerçekçi bir hikâye. Daha ilk satırlarda kitaba hakim olan hüzün sizi yakalıyor. Bu hüzün savaşın ardında kalanlara ait».)*

Тәнкыйтьче А. Гыйләҗев әсәренең асылын бер кеше, бер гаилә язмышы аша сугышны башыннан кичергән меңнәрчә гаилә язмышын үзенең уникаль теле белән бик гади дә, үтемле дә итеп җиткерүендә күрә. «*Süleyman İhtiyar'ın son ümidi de söndü. En küçük oğlu cepheden dönmedi»*. – Әлеге моңсу хикәя сугыштан бердәнбер улын көтеп, өмете өзелгән Сөләйман картның сагышын сурәтләү белән башлана. Әмма чәчәк аткан гөлгә карап та, тәрәзә төбенә килеп кунган кошны күреп тә, яхшыга юраган, бернинди хәбәр юклыктан чарасыз калган ата-ана өчен, бәлки, үлем хәбәре килсә дә, җиңелрәк булыр иде дип уйлаган укучы, әлбәттә, ялгыша, мондый хәбәр ата-ана өчен һич кабул итмәслек бер нәрсә, дип фикер йөртә мәкалә авторы әсәр геройларының психологик халәте хакында уйланып, һәр геройның (Габдулла, аның әти-әнисе, сөйгәне Зәйтүнә) күңел халәтен язучы сүз остасы буларак сурәтләп бирүенә басым ясый. Әлеге геройларның һәрберсенең яшәү көче – Габдулланың кайтыр өмете белән бәйле, һәм бу өмет һич сүнмәячәк. Алар башкалардан читләшә, үз-үзләренә бикләнәләр, ләкин кәүсәсеннән каерылган бер агач ботагы кебек барыбер, яшәргә омтылалар.

Шул рәвешле, мәкалә авторы, А. Гыйләҗев повестеның асыл сыйфатларыннан берсе булган – кешенең психологик халәтен ачу осталыгын аерып күрсәтә һәм әлеге сагышлы тарихның укучыга тәэсир көченең сәбәбен аңлата. Әлеге сагышлы һәм гүзәл хикәянең асыл фикерен язма авторы сугышның татарларның көндәлек тормышына никадәр тирән үтеп кергәнен күрсәтүдә һәм аның фронтта гына бармавын, шул чор кешеләренең сагышы булып чагылыш табуын раслауда күрә.

Мәһмәт Акиф Өзтүркнең (Mehmet Akif Ozturk) «Gunlum Hep Seni Ariyor, Neredesin Sen» («Күңелем һәрчак сине эзли, кайларда син?!») [24, б. 65–66] дип аталган язмасы да әлеге мәкаләдә өйрәнү материалы итеп алынган «Яра» әсәренең тәрҗемәсе басылып чыгу уңаеннан дөнья күрә. Язманың исеме төрек чәчән-җырчысы Нәшәт Әрташның «Neredesin sen?» («Кайларда син?») исемле җырыннан алынган булуы ук – әсәрдәге теманың төрекләр өчен дә чит булмавын күрсәтә.

Автор тарафыннан мәкаләсенең башында китерелгән Садык Һидайәтнең *«Шундый яралар бар тормышта, махау авыруы шикелле әкрен-әкрен һәм ялгызлыктан ашый торган, кимерә торган яралар...»* - дигән сүзләре укучыга язманың асыл фикерен дә, повестьның төп мәсьәләсен дә ачарга ярдәм итә.

М. Өзтүрк үзенең мәкаләсендә Икенче Бөтендөнья сугышын – тарихтагы иң зур сугышларның берсе дип атый һәм дөнья әдәбиятында әлеге сугышка багышланган бик күп әсәрләр иҗат ителгән булуын билгеләп үтә. Сугышның тылда яшәүчеләр тормышына йогынтысын тасвир итүе ягыннан А. Гыйләҗевнең «Яра» повестын Ч. Айтматовның «Анам кыры» әсәренә аеруча якын булуын искәртә.

Әлеге язма мәгълүмати булуы белән аерылып тора: ул төрек укучысын татар язучысы А. Гыйләҗев шәхесе, иҗаты, аның төрек теленә тәрҗемә ителгән әсәрләре турында кызыксындырырлык итеп таныштыра. 160 биттән торган «Яра» әсәренең үзенчәлекле структур төзелеше, каһарманнары, вакыйгалары, сюжеты турында мәгълүмат бирә. Әсәрнең исеменә мөнәсәбәтле, геройларның рухи халәте сугышта югалган улларын зарыгып көтү, өметләнү, өметсезлеккә төшү, тагын өметләнү кебек кичерешләр белән бәйле булуы, әсәр буенча өмет һәм өметсезлек хисләренең алышынып, бәгырьне эзгәләвен билгеләп үтә.

Повестьтагы Зәйтүнә образын сурәтләгәндә, мәкалә авторы Чыңгыз Айтматовның «Кызыл яулыклы Гүзәлкәем» (татарча тәрҗемәсе – «Гүзәлем Әсәл») әсәренә мөрәҗәгать итә. Төркиядә фильм буларак төшерелгән әлеге әсәрдәге (1977 ел) Асия ролен башкарган атаклы төрек киносы йолдызы актриса Түркан Шорайның ирен көткән шикелле Зәйтүнәнең дә Габдулласын көтүе арасында паралельләр үткәреп, төрек укучысына татар язучысы әсәрен, геройлары кичерешләрен күзалларга ярдәм итә.

«Яра» әсәрендә М. Өзтүрк авторның уңышы буларак, бер гаилә тарихын ата-аналары, аларның уллары кичерешләре аша бирелүенә игътибар итә, аеруча сугыш хәсрәтләренең

мәхәббәт тарихы аша җиткерелүен аерып күрсәтә. «Әсәрнең каһарманнары тормыштагыча, повестьта вакыт һәм урын-җир гаҗәеп осталык белән, бик уңышлы бирелгән. Иң мөһиме, вакыйгалар ышандыра, укучы чын мәгънәсендә китапның эченә алып кереп китә. Әсәрнең ахыры сюрприз белән тәмамлана».

Автор, шулай ук, әсәрнең кыйммәтле якларыннан берсе буларак, әсәрдә татар милләтенең йолалары, гореф-гадәтләре мул итеп бирелүен атый һәм фикерен йомгаклап, «„Яра“ соңгы вакытларда мин укыган иң шәп романнарның берсе. А. Гыйләҗевнең бүтән әсәрләренең дә төрек укучысына килеп ирешүен түземсезлек белән көтәм...», – дип яза.

Адаләт Чавдарның (Adalet Çavdar) «Savaş hakkında bugünlerde okunması gereken eserlerden: “Yara”» («Сугыш хакында бүгенге көндә укылырга тиешле әсәрләрдән: «Яра») [25] язмасы төрек укучысын татар язучысының биографиясе, язмышы, Фатих Кутлу тарафыннан төрек теленә тәрҗемә ителгән әсәрләре белән таныштырудан башлана.

*«“**Yara**”, savaş hakkında belki de bugünlerde okunması gereken önemli eserlerden biri. Ayaz Ğıylecev bütün dünya için geçerli ortak bir acıdan bahsediyor ve bu acıyı bir anne ve babanın hikayesi ile anlatmaya başlıyor. Ne kadar klişe bir cümle olarak tınlasa da kulağınızda Yara, okurken okurunu yaralayan romanlardan biri. Kalbinizi avucunuzun içiyle sıkmayı gayet iyi biliyor».* («Яра» сугыш турында бүгенге көндә укылырга тиешле әһәмиятле әсәрләрнең берсе. Аяз Гыйләҗев бөтен дөнья өчен уртак булган хәсрәтне сурәтли һәм бу хәлне әти-әни тарихы аша аңлата башлый. Никадәр кабатланган (клише) бер җөмлә кебек колагыгызда яңгыраса да, «Яра» укыган вакытта укучыны яралый торган әсәр (роман). Йөрәгегезне учы белән кысу серләрен бик әйбәт белә автор.) [25]

Мәкалә авторы, шулай ук әсәрнең асылы – сугышта яраланган, югалган, кулга эләккән татар улларының ата-аналары кичерешләре турында, мәхәббәт көче турында булуын күрсәтә; Габдулланың танымаслык булып үзгәрүе, катлаулы язмышын күрсәтү осталыгын билгеләп үтә. «Озак еллар үткәннән соң очрашу, әлбәттә, фаҗига рәвешендә бирелә. Роман эчендә инсанның җанын парча-парча теткәләгән сәхнәләр бар. Аяз Гыйләҗевнең сурәтләве һәм теле аша сезнең күз алдында авыр бер фильм караган кебек тәэсир кала. Киткән, кайтмаган, кайта алмаган, моннан соң беркайчан да элеккеге кебек була алмаган яшьләр турында уйлаячаксыз. Болар арасында сезнең якыннарыгызның берсе булса, роман роман түгел, чынбарлык булып кабул ителәчәк.

Әсәрдә уртак язмышлар сурәтләнә. Йөз елларча вакыт үтсә дә, сугышның кешелеккә бер файда да китермәвен, аннан бары тик әрнү генә калуын аңламавыбыз өчен оят булырга тиеш», – дигән нәтиҗә ясый ул.

А. Гыйләҗев әсәрен төрек аудиториясе ничек кабул итүен ачыклауда язучы иҗатын, шул исәптән әлеге әсәрен дә фәнни анализларга, бәя бирергә омтылган яшь галимнәр хезмәте дә әһәмиятле. Төркиянең ӦНӨНÜ университетының (Малатья шәһәре) Иҗтимагый фәннәр институты Төрек теле һәм әдәбияты бүлегендә укучы магистрант Бурак Дөнмезнең (Burak Dönmez) «Яра» повесте буенча язган магистрлык эше әсәр турында шактый тирән фикер йөртеп язылган булуы белән аерылып тора. Әлеге хезмәтнең фәнни җитәкчесе – якташыбыз, үз вакытында КФУда эшләгән галимә – профессор Рамилә Яруллина-Йылдырым булуы куанычлы.

175 биттән торган әлеге «Edebiyat ve kültürel değerler bağlaminda tatar yazar Ayaz Giylecev’in Yara romani» / «Татар язучысы Аяз Гыйләҗевнең «Яра» романы әдәби һәм мәдәни кыйммәтләр контекстында» [26] дип аталган әлеге хезмәт татар укучысы өчен төрле яктан кызыклы.

Беренчедән, Төркия вузларында «cagdas edebietler» ягъни «замандаш әдәбиятлар» курсы кысаларында төрки халыклар әдәбиятлары, шул исәптән, татар әдәбияты да өйрәнелүе – уңай күренеш.

Әлбәттә, хезмәтнең чит аудитория – татар әдәбияты, мәдәнияте белән бик якын таныш булмаган төрек укучысы тарафыннан әзерләнеп, шул шартларда яклануы, хезмәтнең шактый зур өлешен татар милләте, аның тарихы, бүгенге торышы, татар халык авыз иҗаты әсәрләре, әдәбият тарихыннан да белешмәләр бирелүен аклый. Эшнең 3 бүлекчәсе – язучы Аяз Гыйләҗевнең татар әдәбияты тарихындагы урыны, язучы турында биографик мәгълүматлар, язучының иҗат юлы, проза, драма өлкәсендәге эшчәнлеге турындагы материалларны туплап бирә.

Эшнең төп өлеше «Яра» романын анализлауга багышланган. Бу өлештә магистрантның А. Гыйләҗев иҗатына мөнәсәбәтле шактый мәкаләләр белән танышкан булуы, әлеге хезмәт аша аларны әйләнешкә кертүе, төрек укучысына танышу

мөмкинлеген тудыру ягыннан да эшнең кыйммәтен билгеләп үтергә кирәк.

Төрек студентының анализ барышында әсәрнең сюжеты, бүлекләренең төзелеш үзенчәлекләре, укучыны кызыксындыру максатыннан кулланылган алымнар, жанр, композиция хакында кызыклы фикерләре бар. Безнең игътибарны аеруча яшь галимнең А. Гыйләҗевнең әлеге повестенда – «Яра» төшенчәсенә аерым игътибар бирүе, әсәрнең мәгънәсен шушы төшенчә аша ачырга омтылуы үзенә тартты.

Магистрлык эше авторы әсәрнең геройларын күздән кичергәндә, аларның барысының да автор тарафыннан «яра» төшенчәсе аша сынау үтүләренә игътибар итә. Яшь галим әлеге сүзнең күп геройларны кешелек сыйфатлары булуы ягыннан сынау ачкычы кебек кулланылуын күрсәтә.

«Яра» сүзенең әсәрдә салынган мәгънәсе турында уйланып, Бурак Дөнмез түбәндәгечә фикер йөртә: «Әлбәттә, беренчедән, әсәр авторы әлеге сүзне туры мәгънәдә, әсәрнең төп каһарманы – Габдулланың күпсанлы тән яралары хакында язган булуын искәртә. Габдулла сугышта берничә кат яралана, берничә тапкыр үлем тырнагыннан ычкына, яралары никадәр күп һәм җитди булуына карамастан, ул һаман исән кала. Әлеге геройны нидер саклый кебек... Әлеге нәтиҗә авторны шушы хәлнең сәбәбен эзләргә; каһарманның әти-әнисе, туганнары, авылдашлары турында уйланырга этәреш ясый» [26, б. 92].

Әле Габдулланың яраларын сурәтләүгә кадәр үк язучы «яра» сүзенең һәм туры, һәм күчерелмә мәгънәдә төрле геройлар язмышын ачуда куллануына игътибар итә:

1921 елгы ачлык күпләрнең күңелендә тирән яра булып кала. Әлеге еллар белән бәйле бер вакыйгага тукталып, студент бу вакыйганы да әлеге төшенчә аша бәяли. Хәллерәк тормышта яшәгән Зөләйха һәм Сөләйман өенә бер төн ярлы Бәдри дип аты чыккан кешенең улы Камали ачлыктан бер кисәк икмәк урлау өчен керә, ләкин Сөләйман аны эләктереп ала. Ачудан балта белән селтәнеп, Камалига кизәнә. Шул вакыт хатыны Зөләйха гомерендә беренче тапкыр иренә каршы төшә, балта аның кулын җәрәхәтли. Шул рәвешле Зөләйха үз тормышын куркыныч астына куеп, Камалины үлемнән, ирен кеше үтерүдән саклап кала. Аннан соң да күршеләренә ярдәмләшеп яши, күпләрне сыерларының сөте белән ач үлемнән коткарып кала. Әлеге авыр елларның истәлеге булып, Зөләйханың кул ярасы, исән калган күршеләренең күңел ярасы кала.

Икенче мисал буларак, эшендә Бурак Дөнмез Шәкүр белән бәйле вакыйганы искә ала. Уларын сугыштан көткән ата-ананың сугыштан кайткан Шәкүр белән очрашуы – сугыш ярасының никадәр тирән, бәгырьләргә үтеп керерлек, өметләрне өзәрлек булуын аңлату өчен кулланылуын аңлап бәяли эшнең авторы. Сугыштан алда төз, биек буйлы, көчле егет булган Шәкүр – тире һәм сөякләргә генә калган, аркасы бөкрәйгән, битендә яра эзләре ярылып ята. «Бу сүзләрдән аңлашылганча, сугыш һәм тоталитар режим кешеләрне физик һәм рухи яктан изә, зәгыйфьләндерә, мескен хәлгә китерә. Шәкүрнең сугышка китәр алдыннан һәм сугыштан кайткач булган физик һәм күңел халәтен күрсәтеп, язучы сугышның нинди аяныч нәтиҗәләргә китергәнен күрсәтә. Физик, тышкы ялардан тыш, егет психологик басым кичергән, куркынган, өметен җуйган икәнлеге аның үз-үзен тотуыннан, сөйләшүеннән дә тоелып тора. Шәкүрнең кайтуы башта Сөләйман белән Зөләйханы өметләндерсәләр, аңардан сугышта булганнарны ишеткәч, ата-ананың өметләре сүнә», – дип бәяли төрек студенты. Бу очракта да геройның тышкы җәрәхәтләре һәм җан яралары – аның игътибар үзәгендә тора.

Зөләйха һәм Сөләйманның Габдулладан башка ике балалары турындагы бүлеккә дә игътибар итә яшь галим. Кызлары Разия турында фикер йөрткәндә дә, әсәрне бәяләүче аның әти-әнисенә игелекле кыз булмавына, ахыр килеп, рус егетенә кияүгә чыгып, авылдан киткән Разия әти-әнисенең йөрәгендә җәрәхәт-яра калдыра, һәм алардан, һәм милләттән ераклаша, – дип бәя бирә. Бу урында яшь галим тагын бер мәсьәләгә – катнаш никахлар мәсьәләсенә дә туктала һәм олы гомумиләштерүгә килә: «Үзенең татар анасын имеп үскәнен оныткан кыз бала образында аша автор башка милләткә кияүгә чыгып, үзенең телен, кем икәнен онытучыларны замана төрки халыкларның барысына да хас булган «милли хасталык» дип бәяли. Әлеге хәлнең милләт фаҗигасе, милләт өчен олы рухи яра булуына басым ясый.

Сөләйман һәм Зөләйханың өметләре булып туган икенче уллары Йосыфҗанның сугышка барып җиткәнче үк мәгънәсез үлеме – ата-ана күңелендә тагын бер яра булып ята.

Эшне башкаручы студент Габдулланың сугышка кадәр үк яратып йөргән кызы –

Зәйтүнә образына аерым тукта. Сугыш аның да өметен өзә, бәхетен кисә. Аның кияүгә чыгуы да – башка өмет калмаудан булуын аңлый яшь галим. Кызның кияүгә чыгуы – аның бәхетсезлеге, Габдулланың эти-әнисе өчен – җан ярасы булып әверелә, диюе белән хаклы.

«Романда Зәйтүнә рухи үсеш кичерә. Ул рухи һәм тән яраларына дучар ителеп, бөтен дөньядан ваз кичкән Габдуллага терәк булу өчен үзе дә елаудан һәм хәсрәттән арыну һәм еллар буе көткән өметенә ирешү өчен көченә. Аяз Гыйләҗев Зәйтүнәне, татар халкына хас булган сабырлык һәм горурлык кебек сыйфатларны, милләтне саклаучы, дәвам иттерүче буларак тәкъдим итә», – дип бәяли.

Шул рәвешле, анализ ахырына әлеге олы хәсрәтләрне кичергән, җан яралары һич басылмаган ата-ананың җан ачысы белән теләгән теләге, догалары – күңел һәм тән яралары белән гарипләнгән Габдалланы соңгы тапкыр туган авылына кайтырга этәрә, үзен-үзе җиңәргә көч бирә, дигән нәтиҗәгә килә төрек студенты. Шушы кадәр сынауларны-яраларны сабырлык белән кичергән ата-ана – Сөләйман белән Зөләйханы язучы Аяз Гыйләҗев соңгы өметләреннән аермаган, уллары белән кавыштырган һәм Зәйтүнәнең дә баласын алып, аның өенә килүе – авторның соң дәрәҗәдә гадел һәм мәрхәмәтле булуын раслый, дип яза.

## Нәтиҗә

Аяз Гыйләҗевның «Яра» повестеның төрек теленә тәрҗемәсе чыкканнан соң әсәр белән танышып, үз фикерләрен укучыга җиткергән авторлар язмалары белән танышу, анализлау, аларның төп фикерен аерып чыгару түбәндәге фикерләргә килергә нигез булды.

Беренчедән, Аяз Гыйләҗев әсәрләрен генә түгел, гомумән татар әдәбиятын дөньяга танытуда әдәби тәрҗеманең никадәр кыйммәтле һәм кирәкле эш булуына тагын бер кат басым ясыйсы килә. Әлбәттә, әлеге юнәлештәге эшчәнлекне планлы рәвештә дәвам иттереп, татар халкының асыл сыйфатларын күрсәткән, тарихи дөреслекне, татарча яшәү принципларын чагылдырган, киңкырлы милли образлар тудырган иң матур әсәрләрне төрле телләргә тәрҗемә итү – кирәкле һәм актуаль эш. Башка телләргә тәрҗемә ителү аша татар әдәби мирасы белән башка халыкларны таныштыру, әдәбиятлар алмашынуга, халыкларның бер-берсен тануына, рухи-әхлакый аңлашуга, мәдәни диалогка юллар ача.

Әлбәттә, әсәрнең мәгънәви асылын, сүз аһәңен чит аудиториягә җиткерүдә тәрҗемәченең осталыгы, телне нечкәлекләренә кадәр белүе, үзенең дә иҗади фикер йөртүе, һәр ике милләтнең дә үзенчәлекле яшәү шартларын, дөньяны кабул итү рәвешен төгәл күзаллавы зарур.

Гыйләҗев текстын төрек укучыларының аңлап кабул итүе, нечкәләп анализлавы, бәяли алулары – әсәр тәрҗемәсенең Фатих Кутлу тарафыннан оста, тирән аңлап, тел үзенчәлекләрен тоеп башкарылган булуын да раслый.

Анализланган мәкалә авторлары, алда күрсәтелгәнчә, «Яра» повестеның мәгънәви тирәнлеген, әсәрнең төп идеясен төгәл аңлап эш итәләр. А. Гыйләҗевның гади бер татар авылында яшәүче кешеләрнең Икенче Бөтендөнья сугышы һәм аннан алдагы еллардагы тормышын күрсәтә. Әсәр геройлары сюжет барышында олы сынау елларын узып, кешелеклелек кыйммәтләрен гәүдәләндереп, татар милләтенең нигез ташларын тәшкил иткән, туган җиргә, Ватанга тугрылыклы, никадәр физик һәм җан җәрәхәте кичергән булсалар да, киң күңелле, башкалар турында борчылып яшәүче, нык үзәкле кешеләр булып кала алганнар, нинди авыр хәлдә дә өметләрен югалтмаганнар дигән нәтиҗә шул хакта сөйли.

«Яра» поветеның исеменә салынган күпкырлы мәгънәне аңлау ягыннан да төрек укучылары ясаган нәтиҗә уйланырга этәрә.

Мәкаләдә анализланган хезмәт авторлары А. Гыйләҗев әсәрендәге иң төп алымга – кешенең рухи дөньясын ачу осталыгына, психологизмга игътибар итәләр. Шуның белән бергә, повестьта татар халкының гореф-гадәтләре чагылышына, аның, нигездә, төрек халкы белән уртак булуына да басым ясала.

## Йомгак

Шул рәвешле, Аяз Гыйләҗев әсәрен тәрҗемәдә укыган төрек аудиториясе «Яра» повестенең төп асылы – Икенче Бөтендөнья сугышы китергән афәтләрнең татар халкы тормышында калдырган тирән хәсрәтләр, афәтләр, мәңге төзәлмәслек тирән яралар турында булуын аңлап, сугышның кешелек дөньясы өчен кирәк булмаган бер афәт, бәхетсезлек чыганагы булуын аңлап эш итә. Әлеге тәрҗемә турында фикер язучылар – татар әдәбиятын, шул исәптән Аяз Гыйләҗев әсәрләрен төрек укучысы арасында тарату,

таныту, әсәрнең төп үзенчәлекләрен аңлату ягыннан да кирәкле, файдалы эш башкаралар.

**Әдәбият**


1. *Ханнанов Р.* Төрек-татар әдәби бәйләнешлары (Турецко-татарские литературные связи) // Казан утлары. 2011. № 2. Б. 78–83.

2. *Сайфулина Ф. С.* Татарско-турецкие культурные и научные взаимосвязи: история и современность // Филология и культура Philologie and Cultur. 2014. № 2 (36). С. 322–326.

3. *Хабибуллина Э. К.* Языковые трансформации при переводе татарской литературы на турецкий язык: дис. ... канд. филол.н. Казань: КФУ, 2016. 283 с.

4. *Сайфулина Ф. С., Валиева А.* Fatih Kutlu: A Translator and advocate of Tatar Literature in Turkey / Ф. Кутлу как переводчик и пропагандист татарской литературы в Турции // Tatarica. 2017. № 2 (9). Б. 42–63.

5. *Сайфулина Ф. С.* Роль переводов тюркоязычной литературы в межкультурном диалоге // Сборник материалов Международной научно-практической конференции «ШАКАРИМОВСКИЕ ЧТЕНИЯ – 2022», посвященной творчеству великого гуманиста, гениального мыслителя, классика казахской литературы Шакарима Кудайбердиева. - Семей: НАО Унив. им. Шакарима, 2022. С. 23–27.

6. *Сайфулина Ф. С.* Современное состояние перевода татарской литературы на тюркские языки // Материалы Международной научно-теоретической конференции «Актуальные вопросы исследования фольклора и истории литературы тюркоязычных народов» (к 90-летию Заслуженного деятеля науки Республики Каракалпакстан, доктора филологических наук, профессора Абдисаита Пахратдинова). Нокус, НГПИ им. Ажинияза, 2023. С. 12–16.

7. *Сайфулина Ф. С., Мингазова Л. И.* Стратегии перевода татарской литературы на тюркские языки: история и современное состояние // Полилингвиальность и транскультурные практики. 2023. Том 20. № 4. С. 659–672.

8. *Бирсел Оруҗ Аслан, Хайретдинова Р. Р., Йусуф Озчобан, Садекова А. Х.* Татарская литература в Турции: особенности бытования и изучения // Tatarica. 2019. № 2 (13). Б. 51–27.

9. *Зарипова-Четин Ч. А., Нурмухаметова Р. С.* Трудности перевода: на примере перевода на турецкий язык повести Галимжана Ибрагимова «Чубарый». // Tatarica. 2023. № 2 (20). С. 7–25.

10. *Ğıylecev A.* Bir Avuç Toprak / А. Гыйләҗев. Өч аршин җир) / тәрҗ. Ф. Котлы. Әнкара: «Бәнгү» нәшр., 2013. 113 б.

11. *Ğıylecev A.* Cuma günü, akşam... / А. Гыйләҗев «Җомга көн, кич белән...» / тәрҗ. Ф. Котлы. Әнкара: «Бәнгү» нәшр., 2013. 202 б.

12. *Ğıylecev A.* «Bahar kervanlari» / Гыйләҗев «Язгы кәрваннар» // тәрҗ. Ф. Котлы // Istanbul: Palto Yayinevi, 2018. 96 б.

13. *Ğıylecev A.* («Yara», / Гыйләҗев «Яра» / тәрҗ. Ф. Котлы // Istanbul: Palto Yayinevi, 2018. 160 б.

14. *Камалетдинова Р.* Кодрәтле сүз иясе // Сөембикә. 1998. № 1. Б. 12–14.

15. *Хәбетдинова М. М.* Аяз Гыйләҗевнең 1986-1991 еллар иҗатына гомуми күзәтү // Гыйләҗев А. М. Сайланма әсәрләр 6 т. – 5 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. 582–617 б.

16. *Миңнуллин Ф.* Балта явызлар кулында: әдәби тәнкыйть мәка-лә-ләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. 143 б.

17. *Сәхапов Ә.* Хакыйкать йөзе // Мирас. 1999. № 6. 102–152 б.

18. *Заһидуллина Д.* 1960–1980 еллар татар әдәбияты: яңарыш мәйданнары һәм авангард эзләнүләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. 346 б.

19. *Хабутдинова М.* Сакральная топонимика в творчестве Аяза Гилязова // Вестник Татарского государственного гуманитарно-педагогического университета. 2010. № 4 (22). С. 235–240.

20. *Хабутдинова М.* Фольклорные образы в повести А.М. Гилязова «Рана» // Фольклор в системе национальных и общечеловеческих ценностей: материалы Международной научно-практической конференции, посвященной 110-летию со дня рождения Хамида Хуснутдиновича Ярмухаметова. Казань: ИЯЛИ, 2014. С. 200–205.

21. *Хабутдинова М.* Хронотоп *дверь* и его функционирование в произведениях Аяза Гилязова // Язык и литературы народов Поволжья: проблемы межкультурной коммуникации: Сбрник трудов 1 Всероссийской интернет-конференции с международным участием. Казань, 1–3 октября 2012 г. Казань: Изд-во Казанский университет, 2012. С. 132–138.

22. *Caner Almaz.* Ortak Acilarin Kitabi / Yara (Уртак хәсрәтләр китабы / Яра). URL: http://www.neokuyorum.org/ortak-acilarin-kitabi-yara/ (мөрәҗәгать итү датасы: 01.03.2024).

23. *Esra Karadoğan.* Savaşin Açtiği Büyük Yara (Сугыш тарафыннан ясалган олы яра) // М. Хәбетдинова шәхси архивыннан. 2018. 2 б.

24. *Mehmet Akif Ozturk.* Gunlum Hep Seni Ariyor, Neredesin Sen («Күңелем һәрчак сине эзли, кайларда син?!») // Тәммуз: Истанбул. 2018. № 12. Б. 65–66.

25. *Adalet Çavdar.* Savaş hakkında bugünlerde okunması gereken eserlerden: «Yara» // edebiyathaber.net (9 Mart, 2018). URL: http://www.edebiyathaber.net/yara-adalet-cavdar (мөрәҗәгать итү датасы: 01.03.2024).

26. *Burak Dönmez.* Edebiyat ve kültürel değerler bağlaminda tatar yazar Ayaz Giylecev'in Yara romani: YÜKSEK LİSANS TEZİ. / DANIŞMAN Prof. Dr. Ramilya Yarullina Yildirim. Malatya: INÖNÜ Üniversitesi, 2023. 174 s.

# ПОВЕСТЬ АЯЗА ГИЛЯЗОВА «РАНА» В РЕЦЕПЦИИ ТУРЕЦКИХ ЧИТАТЕЛЕЙ

**Флёра Сагитовна Сайфулина,**
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
fsaifulina@mail.ru

В литературном тексте писатель выражает свое мировоззрение через жизнь, историю, быт своего народа, раскрывает его национальный менталитет, демонстрирует языковые и изобразительные средства, художественные ресурсы родного народа.

В статье систематизированы и проанализированы рецензии и отзывы турецких читателей на турецкий перевод повести Аяза Гилязова «Яра» («Yara», 2018), выполненный Фатихом Кутлу.

Литературный перевод – важнейшее средство, позволяющее донести до других народов культурные достижения своей нации и добиться взаимопонимания. Благодаря культурному обмену национальным наследием осуществляется литературный и культурный диалог. Данная статья посвящена проблеме продвижения татарской литературы в мире.

В статье констатируется, что произведение Аяза Гилязова получило положительный отклик у турецких читателей. В рецензиях и отзывах по достоинству оценено мастерство писателя: психологизм произведения, достоверность в передаче реальности, детальное изображение национальных образов мира татар и их обычаев. Переводчику удалось без искажения передать особенности художественного мира писателя, богатство его языка.

**Ключевые слова:** Аяз Гилязов, татарская проза, повесть, литературный перевод, Фатих Кутлу, тема войны в литературе